| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| **СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ** |

***Решение*** ***Карар***

**2020 елның 15 декабре** **Чистай шәһәре** **№ 3/7**

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районында
муниципаль хезмәт турында»
2019 елның 23 маендагы 44/3 номерлы
Татарстан Республикасы Чистай муниципаль
районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы «Россия федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү турында» 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Россия Федерациясе законнары нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында» 2019 елның 23 маендагы 44/3 номерлы Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Советы карары белән расланган Чистай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2019 елның 26 сентябрендәге 47/3 номерлы, 2020 елның 20 гыйнварындагы 52/2 номерлы Чистай муниципаль районы Советы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

11 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында күрсәтелгән муниципаль хезмәткәр урынбасары әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында алар тарафыннан тиешле вазыйфа биләү чорында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый.»;

13 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр, хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

20 статьяның 2 пунктындагы 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан муниципаль хезмәт узган чорда хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар формалаштыру һәм әлеге мәгълүматларны мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персональләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә тапшыру, Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;».

2. Чистай муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районы
башлыгы Д.А. Иванов